# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы**
**Урыс авыл җирлегенең Урыс торак пунктында үзара салым кертү турында**

25 ноябрь 2024 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлегенең Урыс торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ЧЫГАРА:

1.«Минзәлә муниципаль районы Урыс авыл җирлегенең Урыс торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан,балачактан инвалид, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, СВОда катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1. Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау – Урыс торак пунктында артезиан скважиналары өчен (насос, материаллар, җайланмалар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, эш өчен килешү буенча түләү);

2. Урыс торак пункты чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (вак таш сатып алу, ташу, салу, грейдирлау, килешү буенча эш өчен түләү).

3.Әлеге карарны Урыс авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// menzelinsk.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
ТР Минзәлә муниципаль районы
Урыс авыл җирлеге башлыгы И.С. Аксюкова